Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № № XIII-5**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 16 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында биләүләре коррупция хәтәрлеге белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган «2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасының 1.2.5. пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасының 1.2.5. пунктын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупция хәтәрлеге белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген расларга (кушымта итеп бирелә).

2.Балык Бистәсе муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупция хәтәрлеге белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 3 июлендәге LI-2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2016 елның 16 ноябрендәге XIII-5 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында биләүләре коррупция хәтәрлеге белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге**

1 бүлек. Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары
1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Совет аппараты җитәкчесе.
2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары
мөстәкыйль бүлек башлыгы.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфасы
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары;
муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе.

2 бүлек. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары
1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Башкарма комитет җитәкчесе;
Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары
мөстәкыйль бүлек башлыгы;
Башкарма комитет органы башлыгы.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфасы
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары;
Башкарма комитет органы башлыгы урынбасары.

3 бүлек. Җирле үзидарәнең башка органында, җирле үзидарәнең башка органы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары
1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе;
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары

мөстәкыйль бүлек башлыгы .
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфасы
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары.